РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЛОКИБЯКОЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Малая, 10,
село Малые Кибя-Кози, 422083
тел.: (884360) 56-2-49 (факс)
E-mail: Mbiz.Tul @tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕЧЕ КИБӘХУҖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кече урам, 10, Кече Кибәхуҗа авылы,
422083
тел.: (884360) 56-2-49 (факс)
E-mail: Mbiz.Tul @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№80** **«24» декабрь 2025 ел.**

**Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 23.03.2022 №6 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль райоы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты,
карар бирә:

1. Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының 23.03.2022 № 6 « Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына (14.11.2022ел №17 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

- 2.5 бүлекнең 2.5.1 пунктына:

А) 4 пунктчада «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү кирәк,» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси мәгълүматларын мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирү һәм аларны эшкәртү кирәк» сүзләренә алмаштырырга;

Б) түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктча өстәргә:

«4.1. Мөрәҗәгать итүче булмаган затның федераль башкарма хакимият органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү өчен ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасы ярдәмендә персональ белешмәләр биргән очракта, мөрәҗәгать итүче өчен мондый затның яисә аның законлы вәкиленең шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын алу күрсәтелгән максатларда таләп ителми.»;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

Җитәкче: И.Г.Заһидуллин